КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 декабрь г.Казань № 1215

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 681 нче карары белән расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 5 август, 681 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 август, 931 нче; 2022 ел, 5 ноябрь, 1178 нче; 2023 ел, 20 апрель, 511 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга бәйле чыгымнарын финанслар белән

тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин